**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 29 апрель № 264

г. Казань

Татарстан Республикасы янгынга каршы хезмәтенең шәхси составына хезмәт таныклыгын рәсмиләштерү һәм бирү тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы янгынга каршы хезмәте турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2008 ел, 15 февраль, 79 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы янгынга каршы хезмәте турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Янгын куркынычсызлыгы турында» 1993 елның 18 маендагы XII-1866 номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы янгынга каршы хезмәте турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2008 ел, 15 декабрь, 79 нчы карары нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Теркәлгән Татарстан Республикасы янгынга каршы хезмәтенең шәхси составына хезмәт таныклыгын рәсмиләштерү һәм бирү тәртибен расларга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы янгынга каршы хезмәте турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2008 ел, 15 февраль, 79 нчы карары белән расланган (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 ел, 10 сентябрь, 656 нчы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) Татарстан Республикасы янгынга каршы хезмәте турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

15 пунктта «вәкаләтле орган» сүзләрен төшереп калдырырга

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков